**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 18 гыйнвар № 15

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекция үзәге» психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен дәүләт автоном белем бирү учреждениесенең исемен үзгәртү турында» 2015 ел, 5 июнь, 420 нче карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекция үзәге» психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен дәүләт автоном белем бирү учреждениесенең исемен үзгәртү турында» 2015 ел, 5 июнь, 420 нче карарына, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. «Росток» психологик-педагогик тернәкләндерү һәм коррекция үзәге» психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен дәүләт автоном белем бирү учреждениесе исемен «Росток» психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге» психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәмгә дәүләт автоном учреждениесенә (алга таба – Үзәк) үзгәртү турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тәкъдимен кабул итәргә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\15.docx